Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
Салаушская средняя общеобразовательная школа
Агрызского муниципального района Республики Татарстан

«Рассмотрено»
Руководитель МО
_______/Ахметзянова Л.М./

Протокол № 1
«29» августа 2023 г.

«Согласовано»
Заместитель директора по УВР
__________/Фархушина Л.Г.
«___»
29 августа 2023 г.

«Утверждаю»
Директор МБОУ Салаушская СОШ
__________/Ахметзянова Л.М.
Приказ № 100_- О___
«31» августа 2023 г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
## по родному (татарскому) языку
## для 10 класса
**Составитель: Ахметзянова Лилия Мухтаровна**

Рассмотрено на заседании
педагогического совета школы.
Протокол №1, от 31 августа 2023 г.

**2023-2024 учебный год**

# 10 нчы сыйныфта татар теле буенча
# эш программасы

:

•

**10нчы сыйныфта татар теленнән урта (тулы) гомуми белем бирүнең максатлары**

1. Телне тулы бер система буларак күзаллау.
2. Татар халкының этник төркемнәре һәм диалектлары, төрки телләр, татар теле, татар язуы, татар халкының рухи, әхлакый, мәдәни мирасы турында мәгълүмат бирү.
3. Татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, тел нормаларын саклап, тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә тел чараларын дөрес кулланып, үзара аралаша һәм аңлаша белү.
4. Тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү.
5. Текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү.
6. Укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

**Төп бурычлар**

1.Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле белем бирү.
2.Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру.
3.Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү.

**Программаның эчтәлеге:**

Милли телне саклау, үстерү — милли мәдәниятне, милләтнең үзен саклау, үстерү дигән сүз;

Туган телнең үсеше, яшәеше; үле телләр;

Татарстан Республикасында татар телен һәм башка халыкларның ана телен ассимиляциядән саклау һәм үстерү чаралары;

1. Татар милли әдәби теленең язма тамырлары: борынгы төрки әдәби тел, иске төрки әдәби тел. иске татар әдәби теле;

Татар халкы кулланган язу төрләре: гарәп, латин графикасына, кириллицага нигезләнгән язу;

Татар әдәби теленеп фонетик, орфоэпик, орфографик, грамматик, стилистик, пунктуацион нормалары;

**Морфология.** Төрле сүз төркемнәренә тупланган мөстәкыйль, ярдәмлек, модаль сүзләрнең сөйләм оештырудагы роле. Татар әдәби теленең сүз байлыгы, тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә, кыскартылма сүзләр;

**Гади һәм кушма җөмлә синтаксисы.** Сүзләр һәм җөмләләр арасында мәгънә мөнәсәбәтләре; сүзләр һәм җөмләләр арасында тезүле һәм ияртүле бәйләнешне тәэмин итүче чаралар; кушымчаларның, теркәгечләрнең, кисәкчәләрнең, бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең язылышы; составында аерымланган кисәге, аныклагычы, тиңдәш кисәкләре, гомумиләштерүче сүзе, кереш яки эндәш сүзе, өстәлмәсе булган гади һәм кушма җөмләләр, аларда тыныш билгеләр;.

2. Әдәби тел нормаларының үсешен халык үсешенә бәйләп аңлата алу. Рун язуы турында төшенчә алу. Гарән язуында әдәби нормаларның үсешен белү. Гарәп язуын уку, ул язуның башлангыч күнекмәләрен алу. Латин графикасының татар телендә үзенчәлекле кулланылышын күз алдына китерү. Кириллицаны кабул итү, анда татар теленең үзенчәлекле авазларының

бирелешен төшенү. Кирилл орфографиясенең төп үзенчәлекләрен белү, аның татар орфоэпиясенә һәм орфографиясенә тәэсирен аңлата белү.

Укучыда булган актив сүзлек запасын арттыру; сөйләмә һәм язма телен, хәтер һәм фикерләү сәләтен үстерү, рухи дөньясын баету; татар теленнән алынган теоретик материалны аңлы үзләштерүне, тел фәнен яхшы белүне тәэмин итү; үзеңне бәяләү һәм башкаларга бәя бирү күнекмәләрен булдыру; дәреслек белән эшләү, конспектлар төзү, белешмә әдәбияттан (төрле сүзлекләрдән, тәнкыйть материалларыннан, фәнни чыганаклардан һ.б.) файдалану күнекмәләре булдыру; киләчәктә фәннәрне ана телендә өйрәнү мөмкинлеген максатка яраклаштырып аңлату.

**Бәйләнешле сойләм үстерү**

Мөстәкыйль рәвештә эш кәгазьләрен (белешмә, акт, васыятьнамә, ышанычнамә, беркетмә) язу, аларны бергәләп тикшерү, редакцияләү;

Төрле стильгә караган чәчмә һәм шигъри әсәрләрне сәнгатьле уку, аларга нигезләнеп, 1 изложение, 1 сочинение язу, аларны тикшерү, төгәлсезлекләрне бетерү;

**Формалаштырылган осталык һәм күнекмәләр**
**(уку елы башына)**

1. Милли телнең иҗтимагый тормыштагы әһәмиятен аңлау, телне саклау – милләтне саклауның төп өлеше икәнен үзләштерү.
2. Язылган текстларның стиль үзенчәлекләрен - аера, эчтәлеген аңлап укый белү; фәнни, рәсми, публицистик стильдә, матур әдәбият стилендә язылган башлангыч текст үзенчәлекләрен тоеп, язма текстта шуларны бирә белү.
3. Татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләрен күз алдына китерү; аралашу һәм үзара аңлашу чарасы буларак язма һәм сөйләмә тел үсештә булсын өчен, аның көндәлек кулланылышын тәэмин итү юлларын белү, ягъни телләр турындагы Законны тормышка ашыру юлларын үзләштерү.
4. Татар тел гыйлеменең татарча укытыла торган башка фәннәр белән бәйләнешен аңлата белү; татар әдәби телен ассимиляцияләнүдән саклау.
5. Татар теленең диалектлары һәм сөйләшләре турында гомуми төшенчәгә ия булу.
6. Тексттагы проблемаларны формалаштыру, текстта күтәрелгән проблемаларны үз дәлилләрен китереп аңлата белү.
7. Изложение һәм сочинениеләрне, сөйләм төренә туры китереп, төрле жанрда яза белү. Язмаларны сыйфатлама, модальлек, эмоциональлек элементларын, стиль үзенчәлекләрен кулланып тулыландыру һәм шомарта алу.
8. Текст яки аның берәр өлеше нигезендә конспект төзү, тезислар әзерли алу, кемгә дә булса характеристика яза белү.
9. Эш кәгазьләреннән хат, белешмә, мәкалә, расписка, акт, гариза һәм беркетмәләрне мөстәкыйль рәвештә яза алу.
10. Сәнгатьле уку, әдәби телдә сөйләм күнекмәләренә ия булу.

**Укучылар үзләштерергә тиешле осталык һәм күнекмәләр**
**(уку елы ахырына)**

1. Әдәби тел нормаларының үсешен халык үсешенә бәйләп аңлата алу.
2. Рун язуы турында төшенчә алу.
3. Гарәп язуында әдәби нормаларның үсешен белү. Гарәп язуын уку, ул язуның башлангыч күнекмәләрен алу.
4. Латин графикасының татар телендә үзенчәлекле кулланылышын күз алдына китерү.

5. Кириллицаны кабул итү, анда татар теленең үзенчәлекле авазларының бирелешен төшенү. Кирилл орфографиясенең төп үзенчәлекләрен белү, аның татар орфоэпиясенә һәм орфографиясенә тәэсирен аңлата алу.
6. Укучыда булган актив сүзлек запасының артуы.
7. Сөйләм һәм язма телнең, хәтер һәм фикерләү сәләтенең үсүе, рухи дөньяның баюы.
8. Татар теленнән алынган теоретик материалның аңлы үзләштерелгән булуы, тел фәнен яхшы белү.
9. Үзеңне бәяләү һәм башкаларга бәя бирү күнекмәләре булу.
10. Дәреслек белән эшләү, конспектлар төзү, белешмә әдәбияттан (төрле сүзлекләрдән, тәнкыйть материалларыннан, фәнни чыганаклардан һ.б.) файдалану күнекмәләре булу.

**Укыту-методик комплекты**

**Дәреслек:**

Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10-11 нче сыйныфлары өчен дәреслек / М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов. – Казан: Мәгариф, 2008.

**Методик ярдәмлекләр**:

1. Вәлиева Ф.С.Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: “Раннур”, 2000.
2. Максимов Н.В. Урта мәктәптә татар теле укыту: Фонетика. Морфология: укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: “Мәгариф”, 2004.
3. “Татар теле. 5-11” интерактив дәреслеге (“Белем.ру” ҖЧҖ, 2009).
4. Диктантлар җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 5-11 нче сыйныфлары өчен. Укытучылар өчен кулланма/З.Н.Хәбибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина. - Казан: Мәгариф, 2006.
5. Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 сыйныфлары өчен. Укытучылар өчен кулланма/Н.В.Максимов, С.М.Трофимова, М.З.Хамидуллина. - Казан: Мәгариф,2005
6. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. - Казан: Яңалиф, 2006
7. Татар теле: Кагыйдәләр, күнегүләр: Урта гомуми белем бирү мәкт. өчен/Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова. - Казан: Мәгариф, 2007
8. Татар теленнән тестлар: Уку-укыту ярдәмлеге/Н.В.Максимов. - Казан: Мәгариф, 2008